**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 18 июль № 523

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү турында

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 ел, 21 июль, ФЗ-108 нче Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру турында» 2013 ел, 10 апрель, 316 нчы карарын, «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2014 ел, 14 май, ТРЗ-31 нче Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары һәм Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының (Татарстанстат) 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру, әзерләү һәм үткәрү буенча үзара хезмәттәшлеген яраштыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгын Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы итеп билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча республика комиссиясен төзергә.

3. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү эшләрен яраштыру һәм оештыру өчен җаваплы Дәүләт

статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) булышлык күрсәтергә.

5. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына:

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) 2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата (алга таба тәгаенләштереп) дәүләт ярдәме алган авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләр исемлеген җибәрергә;

статистик мәгълүматларны җибәрү, исәпкә алу битләре формаларын тутыру өчен җаваплы авыл хуҗалыгы оешмалары вазыйфаи затларын укытуны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырырга;

авыл хуҗалыгы оешмалары тарафыннан исәпкә алу битләрен үз вакытында һәм дөрес итеп тутыруны тәэмин итәргә.

6. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат), авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре урнашкан урыннарны күрсәтеп, картография материалларын җибәрүне «Җир» республика кадастр үзәге» ачык акционерлык җәмгыятенә тәкъдим итәргә.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә 2015 елның 1 августына кадәр Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) 2015 ел дәвамында ветеринария хезмәтләреннән файдаланган шәһәр җирлекләре гражданнары исемлекләрен җибәрергә (алга таба 2016 елның 1 мартына кадәр тәгаенләштереп).

8. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрүне мәгълүмати яктыртуда Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) булышлык күрсәтергә.

9. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына:

2015 елның 1 августына кадәр, 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча район, шәһәр комиссияләре төзергә, комиссия рәисе вазыйфаларын муниципаль берәмлек башлыгына йөкләргә;

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда, Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документларны һәм мәгълүматларны җибәрергә;

авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыручы затларның эшләве өчен һәм исәпкә алу битләрен һәм бүтән авыл хуҗалыгы исәбен алу документларын саклау өчен, телефон элемтәсе һәм җиһазлары булган, саклана торган бүлмәләр, шулай ук транспорт чаралары бирергә;

тиешле административ-территориаль берәмлекләрдә яшәүче гражданнарны авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүдә булышлык күрсәтергә;

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрдән максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органының (Татарстанстат) районнардагы структур бүлекчәләренә 2015 елның 1 августына кадәр (алга таба тәгаенләштереп) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, индивидуаль торак төзелеше өчен җир кишәрлекләре булган һәм (яки) авыл хуҗалыгы хайваннарының күпмедер баш саны булган авыл (шәһәр) торак пунктлары халкының хуҗалыклары, шулай ук гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре исемлекләрен кертергә;

2015 елның 1 августына кадәр җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының хуҗалык кенәгәләрен тулы һәм дөрес итеп тутыруларын тикшерүне төгәлләргә;

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыручы затларның эшләве өчен кирәкле бүлмәләрне саклауны, исәпкә алу битләрен һәм бүтән авыл хуҗалыгы исәбен алу документларын саклауны, шулай ук авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыручы затларның иминлеген тәэмин итәргә;

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә:

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) үткәрү системасы, чәчү мәйданнары һәм (яки) авыл хуҗалыгы хайваннары, кош-корты һәм бал кортларының баш саны булган ведомстволар карамагындагы оешмалар һәм учреждениеләрдәге ярдәмче хуҗалыклар исемлекләрен кертергә;

ведомстволар карамагындагы оешмаларда һәм учреждениеләрдә авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре исәбен алуны үткәрүне тәэмин итәргә;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә исәпкә алу объектлары исемлеген төзү өчен кирәкле күчемсез мөлкәт объектлары турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә белешмәләр алуда Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) булышлык күрсәтергә;

Татарстан Фермерлар һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясенә 2015 елның 1 августына кадәр Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) 2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата (алга таба тәгаенләштереп) крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм индивидуаль эшмәкәрләр исемлекләрен кертергә;

Татарстан Бакчачылар берлегенә 2015 елның 1 августына кадәр Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (Татарстанстат) 2015 елның 1 гыйнвары хәленә карата (алга таба

тәгаенләштереп) гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләре исемлекләрен, шулай ук аларда катнашкан гражданнар исемлекләрен кертергә.

10. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М.Г.Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\523.doc